КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.08.2019 г.Казань № 89-П

Татарстан Республикасы, Казан ш.,Киров районы, Казансу елгасының уң яры, Брюсов ур. тупигы, борын очы адресы буенча урнашкан “Бишбалта бистәсе мөселман зираты” ачылган мәдәни мирас объектын “Адмиралтейство бистәсенең Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” җирле әһәмияткә ия истәлекле урын сыйфатында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү һәм мәдәни мирас объектының сак предметын, чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы федераль закон, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетенең 2016 елның 10 июнендә кабул ителгән “Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектын яки җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертү турында Карар кабул итү турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы Карары, 2017 елның 26 декабрендәге дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсе нигезендә, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы, Казан ш.,Киров районы, Казансу елгасының уң яры, Брюсов ур. тупигы, борын очы адресы буенча урнашкан “Бишбалта бистәсе мөселман зияраты” ачылган мәдәни мирас объектын җирле әһәмияткә ия “Адмиралтейство бистәсенең Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX

гасырлар” мәдәни мирас объекты сыйфатында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренең) бердәм дәүләт реестрына кертергә һәм мәдәни мирас объектының төрен – истәлекле урын – сыйфатында расларга.

2. Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урынының сак предметын расларга (1нче кушымта)

3. Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урыны территориясенең чикләрен расларга (2нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зияраты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урыны территориясеннән файдалану режимын расларга (3нче кушымта)

5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үс өстемдә калдырам.

Рәис И.Н.Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел 21.08 № 89-П
боерыгына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урынының
**сак предметы**

-Казан аръягы Куйбышев сусаклагычы борынында, Бишбалта авылының калкулыклы читендә Казан Кремленең визуаль кабул ителеш зонасындагы зиратның урнашкан урыны (1956 елдан Куйбышев сусаклагычы ярының борынына әйләнгән);

-Казан Кремленнән Адмиралтейство дамбасына кадәр зират күренеше формалашу зонасы;

- Казан Кремленә - Бөтендөнья табигый һәм мәдәни мирас объектына – панорамалы ачу нокталары;

- яр буе һәм тугай зонасы панорамасы: көнчыгышта ясалма беркетелгән җимереклек һәм биеклекнең беркетелгән абсолют билгесе (53 м) белән табигый яр полосасы;

-культуралы катлам - кеше эшчәнлеге процессында йөз елдан артык элек барлыкка килгән һәм археологик предметлары (утырым егәрлеге 2 метрга кадәр) булган кәс катламы астында урнашкан күмерле, көлле һәм б.ш. төрле төстәге комсу һәм балчыксыл җир катламнары;

- кеше тарафыннан йөз елдан артык элек ясалган хуҗалык, җитештерү, йола һәм б.ш. корылмаларның тулысынча яки өлешчә җир астындагы калдыклары һәм фрагментлары (җирләү, торак урыннары, көллек, чокырлар һәм башка объектлар);

- җир өстендәге, өлешчә җир астындагы кабер ташлары һәм скульптура формалары;

- танылган дин эшлеклесе Шейх Биләледдин Әл-Габиди әл-Бохари (1838-1918 еллар.) һәйкәле (граниттан ясалган)

- археологик предметлар, шул исәптән: кеше тарафыннан йөз елдан артык элек балчыктан, таштан, пыяладан, сөяктән, металлдан һәм башка материаллардан ясалган көнкүреш, сугыш предметлары, җитештерү кораллары һәм калдыклары, дини йола предметлары яки аларның фрагментлары, шулай ук йөз елдан артык элек кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә формалашкан, тулысынча яки өлешчә җир эчендә яки өстендә сакланган остеологик материал;

-ландшафтны үзләштерү, татар зираты пространствосын оештыруның традицион ысулын чагыштыручы иҗтимагый пространствоны оештыру мисалы буларак, Казан аръягы территориясен тарихи планлаштыру структурасы фрагментының аутентиклыгы;

- культуралы ландшафтның бөтенлеге;

-җирле рельефка яраклы рәвештә ориентацияләүнең төп композиция күчәре буларак, төп тарихи Брюсов урамы трассасы;

- табигый яшелләндерүнең төрләре ((агачлыклар, аланнар) ;

-яшел утыртмаларның дендрология составы  (юкә, каен, корычагач)

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел 21.08 № 89-П
боерыгына 2нче кушымта

Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урыны **территориясенең чикләре**

Мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең **картасы (схемасы)**



Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урыны территориясенең **картографик тасвирламасы**

**I зонасы** түбәндәге чикләрдә:

Зират территориясенең көньяк-көнчыгышында 1,1 ноктасыннан 1,4 ноктасына кадәр – сынык сызык ясап, утыртмаларының чиге буйлап;

Көньяк-көнбатышта – 1,4 ноктасыннан 1,7 ноктасына кадәр – Идел елгасы яры буйлап;

Төньяк-көнбатышта 1,7 ноктасыннан 1,9 ноктасына кадәр - гаражларның кадастр чиген исәпкә алып;

Төньяк-көнчыгышта 1,9 ноктасыннан 1,13 ноктасына кадәр (1,1 ноктасы белән тәңгәл килә).

**II зонасы** - аеруча катгый режимлы идарә итү зонасы түбәндәге чикләрдә:

Көнбатышта 2.1 ноктасыннан 2.2 ноктасына кадәр – зираттан көньяк-көнбатышта кадастр кишәрлеге чиге буйлап, төзелеш өчен кишәрлекнең металл коймасы буенча; 2.2 ноктасыннан 2. 3 ноктасына кадәр – гаражлар территориясенең кадастр чикләре белән кисешкәнче туры линия буйлап; 2.3 ноктасыннан 2. 5 ноктасына кадәр – гараж территорияләренең төньяк-көнбатыш кадастр чикләре буйлап; 2.5 ноктасыннан 2.6 ноктасына кадәр – зиратның төньягындагы төзелеше бетмәгән объект территориясе чикләренә иң кыска ара буйлап;

Төньякта 2.6 ноктасыннан 2.7 ноктасына кадәр – төзелеше тәмамланмаган объект территориясе чикләре буйлап , 2.7 ноктасыннан 2.9 ноктасына кадәр – археология объектлары табылган калкулык әйләнәсендә сынык линия, 2.9 ноктасыннан 2.10 ноктасына кадәр төньяк-көнчыгышта туры линия буйлап яр линиясе белән кисешкәнче 53 м билгесенә кадәр, 2.10 ноктасыннан 2.15 ноктасына кадәр – 53 м билгесендә яр линиясе чиге буйлап, 2.15 ноктасыннан 2.16 ноктасына кадәр – дамба чиге буйлап катер станциясе причалына кадәр, дамба буйлап туры линия буенча 2.16 ноктасыннан 2.17 ноктасына кадәр. Аннан көнчыгышта һәм көньякта 2.17 ноктасыннан 2.68 ноктасына кадәр – Куйбышев сусаклагычының яр линиясе чиге буйлап 53 м билгесендә.

Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урыны территориясенең
**борылыш нокталары**

| Нокта | Нокталарның 1984 елгы (WGS-84) Бөтендөнья геодезик координатлар системасында координатлары | | Нокталарның җирле координатлар системасында координаты (МСК-16) | |
|---|---|---|---|---|
| | N | E | X | Y |
| **I зона** | | | | |
| 1.1 | 49°03'47,9 | 55°47'28,65 | 1301984,31 | 475993,63 |
| 1.2 | 49°03'47,3 | 55°47'27,97 | 1301973,79 | 475972,53 |
| 1.3 | 49°03'47,3 | 55°47'27,04 | 1301973,42 | 475943,78 |
| 1.4 | 49°03'46,1 | 55°47'26,43 | 1301953,31 | 475925,11 |
| 1.5 | 49°03'42,5 | 55°47'27,60 | 1301889,48 | 475961,17 |
| 1.6 | 49°03'39,3 | 55°47'28,15 | 1301834,38 | 475978,26 |
| 1.7 | 49°03'37,4 | 55°47'28,72 | 1301801,83 | 475995,89 |
| 1.8 | 49°03'37,9 | 55°47'29,17 | 1301809,66 | 476009,68 |
| 1.9 | 49°03'38,3 | 55°47'29,47 | 1301817,11 | 476018,89 |
| 1.10 | 49°03'39,4 | 55°47'29,45 | 1301835,78 | 476018,39 |
| 1.11 | 49°03'41,4 | 55°47'29,24 | 1301870,04 | 476012,04 |
| 1.12 | 49°03'44,1 | 55°47'29,10 | 1301918,57 | 476007,64 |
| 1.13 | 49°03'46,5 | 55°47'28,84 | 1301959,77 | 475999,45 |
| **II зона** | | | | |
| 2.1 | 49°03'36,3 | 55°47'27,68 | 1301781,21 | 475963,52 |
| 2.2 | 49°03'37,0 | 55°47'28,67 | 1301794,79 | 475994,26 |
| 2.3 | 49°03'37,2 | 55°47'29,66 | 1301797,86 | 476024,82 |
| 2.4 | 49°03'37,4 | 55°47'29,96 | 1301801,24 | 476034,12 |
| 2.5 | 49°03'37,4 | 55°47'30,15 | 1301801,24 | 476040,10 |
| 2.6 | 49°03'37,1 | 55°47'30,46 | 1301796,54 | 476049,72 |
| 2.7 | 49°03'37,9 | 55°47'30,60 | 1301809,60 | 476054,06 |
| 2.8 | 49°03'39,1 | 55°47'31,44 | 1301830,50 | 476079,94 |
| 2.9 | 49°03'42,9 | 55°47'31,51 | 1301896,59 | 476081,96 |
| 2.10 | 49°03'44,6 | 55°47'30,98 | 1301925,77 | 476065,73 |
| 2.11 | 49°03'44,8 | 55°47'30,91 | 1301929,42 | 476063,70 |
| 2.12 | 49°03'45,1 | 55°47'30,74 | 1301934,55 | 476058,27 |
| 2.13 | 49°03'45,3 | 55°47'30,62 | 1301938,77 | 476054,67 |
| 2.14 | 49°03'45,4 | 55°47'30,57 | 1301940,79 | 476052,94 |
| 2.15 | 49°03'45,7 | 55°47'30,44 | 1301946,39 | 476049,12 |
| 2.16 | 49°03'46,8 | 55°47'29,99 | 1301964,21 | 476035,19 |
| 2.17 | 49°03'47,5 | 55°47'29,67 | 1301976,32 | 476025,27 |
| 2.18 | 49°03'47,6 | 55°47'29,55 | 1301979,60 | 476021,59 |
| 2.19 | 49°03'47,8 | 55°47'29,40 | 1301982,65 | 476016,87 |
| 2.20 | 49°03'48,1 | 55°47'29,23 | 1301986,77 | 476011,67 |
| 2.21 | 49°03'48,1 | 55°47'29,07 | 1301987,83 | 476006,61 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2.22 | 49°03'48,1 | 55°47'28,91 | 1301987,35 | 476001,80 |
| 2.23 | 49°03'48,1 | 55°47'28,74 | 1301987,88 | 475996,38 |
| 2.24 | 49°03'48,2 | 55°47'28,65 | 1301988,76 | 475993,80 |
| 2.25 | 49°03'48,3 | 55°47'28,53 | 1301991,18 | 475990,01 |
| 2.26 | 49°03'48,3 | 55°47'28,49 | 1301991,66 | 475988,60 |
| 2.27 | 49°03'48,3 | 55°47'28,44 | 1301991,43 | 475987,26 |
| 2.28 | 49°03'48,2 | 55°47'28,34 | 1301989,85 | 475984,03 |
| 2.29 | 49°03'48,2 | 55°47'28,27 | 1301989,50 | 475981,84 |
| 2.30 | 49°03'48,2 | 55°47'28,20 | 1301989,81 | 475979,88 |
| 2.31 | 49°03'48,3 | 55°47'28,08 | 1301991,58 | 475976,03 |
| 2.32 | 49°03'48,4 | 55°47'27,99 | 1301992,30 | 475973,26 |
| 2.33 | 49°03'48,4 | 55°47'27,85 | 1301992,32 | 475968,90 |
| 2.34 | 49°03'48,1 | 55°47'27,00 | 1301987,32 | 475942,81 |
| 2.35 | 49°03'48,0 | 55°47'26,80 | 1301985,81 | 475936,63 |
| 2.36 | 49°03'47,8 | 55°47'26,52 | 1301982,05 | 475927,71 |
| 2.37 | 49°03'47,6 | 55°47'26,38 | 1301979,49 | 475923,62 |
| 2.38 | 49°03'47,3 | 55°47'26,25 | 1301973,79 | 475919,47 |
| 2.39 | 49°03'46,8 | 55°47'26,14 | 1301964,36 | 475916,22 |
| 2.40 | 49°03'46,5 | 55°47'26,13 | 1301958,95 | 475915,85 |
| 2.41 | 49°03'46,0 | 55°47'26,15 | 1301950,66 | 475916,46 |
| 2.42 | 49°03'45,7 | 55°47'26,18 | 1301945,81 | 475917,30 |
| 2.43 | 49°03'45,2 | 55°47'26,30 | 1301936,65 | 475921,10 |
| 2.44 | 49°03'44,3 | 55°47'26,44 | 1301920,78 | 475925,28 |
| 2.45 | 49°03'43,7 | 55°47'26,48 | 1301911,13 | 475926,69 |
| 2.46 | 49°03'43,3 | 55°47'26,55 | 1301904,60 | 475928,87 |
| 2.47 | 49°03'43,1 | 55°47'26,65 | 1301900,88 | 475931,78 |
| 2.48 | 49°03'43,0 | 55°47'26,75 | 1301898,42 | 475934,78 |
| 2.49 | 49°03'42,9 | 55°47'26,77 | 1301897,07 | 475935,57 |
| 2.50 | 49°03'42,5 | 55°47'26,72 | 1301890,51 | 475934,02 |
| 2.51 | 49°03'42,3 | 55°47'26,73 | 1301885,93 | 475934,37 |
| 2.52 | 49°03'42,1 | 55°47'26,78 | 1301882,34 | 475935,95 |
| 2.53 | 49°03'41,8 | 55°47'26,86 | 1301878,55 | 475938,19 |
| 2.54 | 49°03'41,5 | 55°47'26,80 | 1301872,55 | 475936,51 |
| 2.55 | 49°03'41,2 | 55°47'26,78 | 1301867,23 | 475935,77 |
| 2.56 | 49°03'41,0 | 55°47'26,83 | 1301863,24 | 475937,27 |
| 2.57 | 49°03'40,7 | 55°47'26,96 | 1301858,96 | 475941,23 |
| 2.58 | 49°03'40,4 | 55°47'27,23 | 1301853,12 | 475949,69 |
| 2.59 | 49°03'39,4 | 55°47'27,08 | 1301835,12 | 475944,96 |
| 2.60 | 49°03'39,1 | 55°47'27,07 | 1301831,52 | 475944,85 |
| 2.61 | 49°03'38,8 | 55°47'27,10 | 1301826,12 | 475945,71 |
| 2.62 | 49°03'38,5 | 55°47'27,16 | 1301820,79 | 475947,61 |
| 2.63 | 49°03'38,1 | 55°47'27,31 | 1301814,13 | 475952,12 |
| 2.64 | 49°03'37,9 | 55°47'27,45 | 1301810,44 | 475956,60 |
| 2.65 | 49°03'37,7 | 55°47'27,59 | 1301806,23 | 475960,82 |
| 2.66 | 49°03'37,4 | 55°47'27,58 | 1301801,22 | 475960,67 |
| 2.67 | 49°03'36,9 | 55°47'27,61 | 1301792,97 | 475961,59 |
| 2.68 | 49°03'36,5 | 55°47'27,66 | 1301785,34 | 475962,95 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
2019 ел 21.08 № 89-П
боерыгына 3нче кушымта

Татарстан Республикасы, Казан ш., Киров районы адресы буенча урнашкан җирле әһәмияткә ия мәдәни мирас объекты “Адмиралтейство бистәсе, Бишбалта авылы мөселман зираты, XVI-XX гасырлар” истәлекле урыны территориясеннән **файдалану режимы**

Мәдәни мирас объекты территориясенең чикләрендә:

**1 зона: рөхсәт ителә:**

1.1. Мәдәни мирас объектларын саклау буенча федераль орган тарафыннан бирелгән рөхсәт кәгазе нигезендә һәйкәлне өйрәнү буенча, шул исәптән археология предметларын эзләү һәм гамәлдән чыгару максаты белән, эшләр алып бару;

1.2. Археологик мирас объектының сакланышын тәэмин иткән очракта, шулай ук күрсәтелгән объектларга керүне археологик кыр эшләрен 73-ФЗ федераль законына яраклы рәвештә уздыру шарты белән, Казансу елгасының археологик мирас объекты урнашкан ярында һәм акваториясендә археологик тикшеренүләр уздыру;

1.3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрен), шул исәптән мәдәни-танып белү туризмын үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне популярлаштыру буенча эш алып бару;

1.4. Һәйкәл территориясе чикләрендә мәдәни мирас объектларын саклап калу, файдалану, популярлаштыру һәм саклау өлкәсендә вәкаләтле орган тарафыннан килештерелгән җир, мелиорация, хуҗалык, төзекләндерү эшләре алып бару, яки һәйкәлнең сакланышын тәэмин итү проектлары, археологик кыр коткару эшләре планнары нигезендә һәйкәлне саклап калу буенча эшләр алып бару;

1.5.Ландшафтның элегрәк, Куйбышев сусаклыгычын су басканчы, югалган тарихи кыйммәтле элементларын һәм параметрларын (зират урнашкан табигый кәсле калкулык) торгызу;

1.6. Мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештерелгән проектлар нигезендә һәйкәлне музейлаштыру буенча чаралар уздыру;

1.7. Гамәлдәге законнар нигезендә гражданнарның һәйкәлгә ирекле керүен тәэмин итү;

1.8. Гомуми файдаланудагы территорияне формалаштыручы җир кишәрлекләре чикләре буйлап, 2,0 метрдан да биек булмаган үтә күренмәле коймалар, биеклеге 3 метрдан артмаган үтә күренмәле капкалар һәм 2,5 метрдан да артмаган ян капкалар урнаштыру;

1.9. Яр буйлап урнашкан керү урыннарын, карау юлларын һәм күзәтү мәйданчыкларын төнлә яктыртуны оештыру;

1.10. 2,5 метрга кадәр биеклектәге мемориаль һәм мәгълүмати билгеләр, монументаль-декоратив сәнгать әсәрләре, кече архитектура формалары урнаштыру;

1.11. Архитектура мохите элементлары характеристикаларына җавап бирә торган вандалга каршы урам җиһазлары (эскәмияләр, урналар) урнаштыру;

1.12. Вакыйга уңаеннан булган (шул исәптән бәйрәмчә бизәлешне дә кертеп), вакытлы мәгълүмати-декоратив бизәлеш элементларын (мобиль мәгълүмат конструкцияләре) урнаштыру;

1.13. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары уздыру;

1.14. Җәяүлеләр өчен традицион яки табигыйләрен имитацияләүче материаллар (ак таш, гранит, гравий катнашмасы) кулланып эшләнгән пар үткәрүче өслекле юллар булдыру;

1.15. Шәһәр панорамасы күренеп торган мәданчыклар оештырып, территорияне төзекләндерү; территорияне төзекләндергәндә гражданнарның мәдәни мирас объектына керә алу мөмкинлеген тәэмин итү;

1.16. Кыйммәтле агач токымнарын саклап калу, урам буйларында кыйммәтле агачлардан торган аллеялар утырту, чәчәк түтәлләре һәм газоннар ясау;

1.17. Зират янәшәсендәге территорияләрдән һәм сөзәклек өстеннән су китүен тәэмин итүче чаралар күзаллап, авышлыкны ныгытып, зират рельефы билгеләрен бозмыйча ярны ныгыту эшләре алып бару;

1.18. Үлән чабу, территорияне коры-сарыдан, үзе һәм бәбәкләрдән үсеп чыккан агачлардан һәм куаклардан чистарту;

1.19. Әйләнә-тирә территориядән өслек суларының китүен тәэмин итүче чаралар күзаллап, зират җире дәрәҗәсенең билгесен киметү (соңрак эшләнгән вак ташлы өслекне юк итү)

**2. Тыела:**

2.1. Җир, төзелеш, мелиорация һәм башка эшләр башкару; мәдәни мирас объектын яки аның аерым элементларын саклау, мәдәни мирас объектының тарихи-мәдәни яки табигый мохитен саклау эшләре искәрмә булып тора;

2.2. Куллану һәм сәнәгать җитештерүе калдыкларын (шул исәптән радиоактив) күмү урыннарын, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен, кәрәзле элемтәнең антенна вышкаларын, нефть һәм газ үткәргечләрне урнаштыру;

2.3. Динамик йогынты ясаучы һәм транспорт агымнарын тагын да арттыруга шартлар тудыручы инженер-төзелеш эшләрен үткәрү;

2.4. Агачларның кыйммәтле төрләрен (имән, юкә, корычагач) кисү; санитар кисү искәрмә булып тора;

2.5. Реклама конструкцияләрен, бик зур, зур һәм урта форматтагы аерым торучы конструкцияләрне биналарда һәм корылмаларда урнаштыру;

2.6. Тарихи сөзәклекне аның характерын, авышу почмагын һәм биеклек билгеләрен сизелерлек үзгәртә торган конструкцияләр белән ныгыту;

2.7. Ял итү урыннары, бивуаклар ураштыру, учак ягу.

**2 зона: рөхсәт ителә:**

3.1. Мәдәни мирас объектларын саклау буенча федераль орган биргән рөхсәт кәгазе нигезендә һәйкәлне өйрәнү буенча, шул исәптән археология предметларын эзләү һәм гамәлдән чыгару максаты белән, эшләр алып бару;

3.2.Булган бина, корылмаларны капиталь ремонтлау һәм и реконструкцияләү;

3.3. Билгеләнгән биеклек параметрларын (11 м) исәпкә алып, чикләнгән төзелеш эшләре алып бару, дисгармоник корылмаларны сүтү ( демонтаж);

3.4. Булган коммуналь хезмәт күрсәтү объектларын (инженерлык инфраструктурасын), автомобиль юлларын, башка объектларны капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, тирәлек элементларының характеристикаларына туры килә торган аерым торган яктырту җиһазларын урнаштыру;

3.5. Мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештереп, вакытлы һәм ярдәмче корылмалар: стационар булмаган сәүдә объектлары, тукталыш модульләре төзү;

3.6. Җәяүлеләр һәм велосипедчылар йөрү өчен юллар, вакытлыча ачык парковкалар оештыру;

3.7. Җәяүлеләр мәйданчыкларының, тротуарларның өслегендә традицион яки табигыйләрне имитацияләүче материаллар (таш, гранит, гравий катнашмасы) кулланып, территорияне төзекләндерү;

3.8. Агачларның кыйммәтле төрләрен саклап калу, аллеялар буйлап кыйммәтле төр агачлар утырту, чәчәклекләр һәм газоннар ясау;

3.9. Рельефны саклап калу, сөзәклекләрне ныгытып үлән чәчү;

3.10. Яңгыр һәм кар суларын агызуны оештыру, төзекләндерү

**4. Тыела:**

4.1. Вәкаләтле мәдәни мирас объектларын саклау органы белән килештермичә җир, төзү, мелиорация һ.б. эшләр алып бару

4.2. Авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать өлкәсенә караган биналар һәм корылмалар төзү, янгын куркынычы тудыручы предприятиеләр, көчле йөк агымнары булдыручы объектлар урнаштыру;

4.3. Булган объектларны аларның параметрларын үзгәртеп (биеклеге 11м артык, габаритлары һәм актив силуэтлары) реконструкцияләү;

4.4. Куллану һәм сәнәгать җитештерүе калдыкларын (шул исәптән радиоактив) күмү, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен, кәрәзле элемтәнең антенна вышкаларын, нефть һәм газ үткәргечләрне урнаштыру;

4.5. Археологик саклау-коткару эшләре үткәрмичә, җир өстеннән инженер коммуникацияләре (су, җылылык, электр, газ, элемтә, канализация челтәрләрен) уздыру;

4.6. Динамик йогынты ясаучы һәм транспорт агымнарын тагын да арттыруга китерүче  инженер-төзелеш эшләрен үткәрү;

4.7. Мәгълүмат кырының бер як мәйданы 2,0 кв. метрдан  һәм биеклеге 2,5 метрдан арткан аерым торучы тышкы мәгълүмат чараларын һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру;

4.8. Ял итү урыннары, бивуаклар уранштыру, учак ягу.

4.9.Агачларның кйыммәтле төрләрен (имән, юкә, корычагач) кисү; санитар кисү искәрмә булып тора.

Приказ подготовил:

Начальник отдела археологии и
учета объектов культурного наследия А.Г.Нуриев

Согласовано:

Заместитель председателя А.Р.Саляхов

Начальник отдела правовой,
организационной и кадровой
работы Н.В.Прохорова